# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге составына керүче Кече Кирмән торак пунктында 2025 елга үзара салым кертү турында

№ 7 17 октябрь 2024 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлегенең Кече Кирмән торак пунктында узган гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге Кече Кирмән торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2025 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:
- Кече Кирмән торак пунктында урамнарны яктырту буенча энергия саклаучы лампалар алу һәм урнаштыру;
- Кече Кирмән торак пунктында традицион күмү урыннарын төзекләндерү ремонт, коймалар кору, (зират территориясендә агачларны кисү);
- Кече Кирмән торак пункты- Төзүчеләр һәм Совет урамнарындагы юлларны вак таш җәеп ремонтлау. (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Кече Кирмән торак пунктындагы юлларны кардан чистарту.

3. Әлеге карарны Кече Кирмән авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Кече Кирмән авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе Х.Х.Мубаракшин